«Рассмотрено»
Руководитель методического объединения
учителей начальных классов
_________/Тухбатуллина Э.М./

Протокол № 1от
« 26 » августа 2017 г

«Согласовано»
Зам. директора по УР
_________/ Исмагилова Г.Т. /

« 28» августа 2017 г.

« Утверждено»
Директор школы
_________/Сабирзянова Г.Т. /

Приказ __№71__от
«28 » августа 2017 г.

МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «САРМАНОВСКАЯ СРЕДНЯЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ШКОЛА» САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

## ЛИТЕРАТУРНОЕ ЧТЕНИЕ НА ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ, 4 б класс

предмет, класс

**Ханнанова Венера Марселевна, первая квалификационная категория**

ФИО, категория

Рассмотрено на заседании
педагогического совета
протокол № 1от
«28» августа 2017 г.

2017-2018 учебный год

Каралды
Башлангыч сыйныф укытучыларының мәктәп методик берләшмә җитәкчесе ______ Тухбатуллина Э.М.
Беркетмә № 1
« 26 » август 2017 ел.

Килешенгән
Укыту эшләре буенча директор урынбасары
______ Исмагилова Г,Т,.
"28" август 2017 ел

Раслыйм
Мәктәп директоры
______ Сабирзянова Г.Т..
Приказ № 71
« 28 » август 2017 ел

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы МББУ "Сарман урта гомумбелем бирү мәктәбе"

# ӘДӘБИ УКУ ФӘНЕННӘН ЭШ ПРОГРАММАСЫ

4 нче б сыйныф

**Ханнанова Венера Марсель кызы, беренче квалификацион категорияле башлангыч сыйныф укытучысы**

Каралды
Мәктәп педагогик советы утырышы беркетмәсе №1
28 август 2017 ел

**2017 – 2018 нчы уку елы**

**Тематик планлаштыру**

**Әдәби уку**

4 нче сыйныф өчен әдәби уку фәненнән эш программасы федераль дәүләт белем стандартына,«Сарман гомуми урта белем бирү мәктәбе» МБГББУнең 2017-2018 нчы уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.

Программа елга 102 сәгатькә (атнага 3 сәгать) каралган.

УМК «Перспективалы башлангыч мәктәп»

Программа үтәлү өчен түбәндәге укыту-методик әсбаплар кулланыла:

1.Әдәби уку: татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 4 нче с-фы өчен дәреслек. 3 кисәктә.1 нче кисәк/(Г.М.Сафиуллина һ.б.,рәссамы Ф.Ризаева).-Казан: “ Мәгариф-Вакыт” нәшр.,2014.

2. Әдәби уку, татар телендә башл. гомуми белем бирү мәкт. 4 нче сыйныфында эшләүче укытучы өчен дәреслек/( Г.М.Сафиуллина һ.б.,рәссамы Ф.Ризаева).- Казан: “ Мәгариф-Вакыт”,2014.

**Укыту предметына гомуми характеристика. Укыту процессының төп характеристикасы.**

Әдәби уку фәненнән эш программасы “Перспективалы башлангыч мәктәп” концепциясе һәм икенче буын гомуми белем бирү федераль дәүләт стандартлары таләпләренә туры килә.

Әдәби уку – башлангыч мәктәптә төп предметларның берсе. Бу фән аша кече яшьтәге мәктәп баласына һәрьяклы белем бирелә. Башлангыч мәктәптә әдәби уку дәреслекләренең төп **максаты** – 4 ел уку дәверендә балада дөрес һәм йөгерек уку күнекмәләре булдыру, халык авыз иҗаты, язучы һәм шагыйрьләр әсәрләре белән якыннан таныштыру, чәчмә һәм шигъри әсәрләрне укып эстетик ләззәт алырга өйрәтү.

Төп идеяләр берничә һәм, бу идеяләрне тормышка ашырмыйча торып, максатка ирешергә мөмкин түгел.

**Беренче идея**. Уйдырмалар (мифлар) , халык авыз иҗаты белән автор әсәрләренең бәйләнеше турында дөрес күзаллау булдырырга кирәк.

**Икенче идея.** Әдәбият дәресләрендә, ашыкмыйча гына, әдәби образ төшенчәсен кертә бару сорала.

**Өченче идея**. Кече яшьтәге мәктәп баласын башта халык аваз иҗаты әсәрләре жанрларын, ә соңыннан әдәби жанрларын үзләрен дә аера белергә өйрәтергә кирәк.

**Дүртече идея**. Кече яшьтәге мәктәп баласын шигъри әсәрләрне яратырга һәм аларны укып ләззәтләнә белергә өйрәтергә кирәк.

Укуга аңлы караш, уку күнекмәләре формалаштыру – “Әдәби уку” курсының **төп бурычы**.

Әдәби уку курсының төп этик бурычларыннан булган әхлак, экология, ватанпәрвәлык мәсьәләләре дәреслектә турыдан-туры үгет-нәсыйхәт бирү, махсус өйрәтү юлы белән хәл ителми, ә бәлки баланың табигать, тормыш-көнкүреш һәм яшәү тәҗрибәсенә нигезләнеп чишелә.

«Әдәби уку» укыту-методик комплекты түбәндәге **мәсьәләләрне** хәл итә.

1. «Перспектив башлангыч мәктәп» комплекты чишәргә тиешле **гомумдидактик бурычлар**: укучы үзенә кирәкле информацияне «Эчтәлек»;битенә карап таба белергә; исеме буенча текстның эчтәлеген күзалларга; күзәтү эшчәнлеген формалаштырырга *(әдәби һәм сәнгать исәрләреннән аерым детальләрне таба, барлык ваклыклары белән сөйләп бирә)* һәм гомумиләштерергә *(аерым детальләргә нигезләнеп, таралган төрле мәгълүматларны берләштереп, бербөтен картина тудырырга);* «акыллы өлкәннәр» белән хат аша аралашу ихтыяҗы формалаштырырга тиеш.

2. Бала яшенә туры килә торган **теоретик бурычлар**:

а) хайваннар турындагы әкият үзенчәлекләре белән таныштыру: татар халык әкиятләренең, берьяктан, башка халыкларның хайваннар турындагы әкиятләренә охшаш булуы *(төп геройлары — хайваннар, еш кына бер ук төрле мөнәсәбәтләргә керәләр),* икенче яктан, бер-берсеннән аерылуы *(төп геройлар — башка төрле хайваннар, бер-берсе белән мөнәсәбәтләре бөтенләй башка төрле);* хайваннар турышдагы автор әкиятләренең еш кына  халык әкияләренә нигезләнүе *(башлангыч сыйныфларда әле автор нигезләнүе термин буларак әйтелми);* халык әкиятләрендә аерым хайваннарның патшалык итүе *(баш булуы);* хайваннар турындагы әкият героеның һәрвакытта көчсезләрне яклаучы гына түгел, еш кына хәйләкәр, тиктормас, көлкегә калучы икәнлеге турында төшенчә бирү;

3. **Әхлакый бурычлар**: күзәтүчәнлек, хыяллана белүчәнлек, дуслар белән аралашу, ярата һәм яратыла белү – байлык һәм рухи кыйммәт икәнлеге турында күзаллау булдыру;

4. **Эстетик бурычлар**: матурлык - ул сине чолгап алган тирәлек, бары тик аны күрә белергә кирәкле турында төшенчә бирү;

5. **Сөйләм телен үстерү бурычлары** -текстта ориентлаша белергә өйрәтү: әсәрләрне өлешләргә бүлү, кирәк урынны табын укып күрсәтү, хис белән белдерелгән өзекнең эчтәлеген ачыклау; әдәби әсәрләргә бәя бирелгәндә һәм сәнгать әсәрләрен караганда предметка  - бу «синең» әсәрне аңлау;идеяң икәнен җайлап төшендерү.

Дәреслек һәм  дәреслек-хрестоматия, мөстәкыйль эш дәфтәреструктуралары һәм идея эчтәлекләре буенча бер – берсенә бәйләнеп килә. Мәсәлән, дәреслекнең «Күзәтәбез һәм тәэсирләр белән уртаклашабыз»,  «Чагыштырулар серенә  төшенәбез», «Кешеләрнең хыялларын

аңларга тырышабыз»,  « Ярату турында», “ Хикмәтле тормыш тәҗрибәсе туплыйбыз”, Көлке серләре”, “Герой ничек туа?”, “Үткәннәр белән хәзергене чагыштырабыз” бүлекләренә дәреслек – хрестоматиянеңһәм эш дәфтәреннең шул ук бүлекләре туры килә.

Дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәре дә бер үк максатларны тормышка ашыра

**Предметның укыту планындагы урыны**

Программа елга 102 сәгатькә (атнага 3 сәгать) каралган.

**Искәрмә**:“Сарман урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль белем бирү бюджет учреждениесенең “Укыту предметы, курсы, дисциплинасының эш программасы турында  “ гы 29 нчы август, 2016 нчы елда педсоветта каралган (беркетмә № 1) һәм мәктәп директоры тарафыннан 2016 нчы елның 29 нчы августында чыккан 109 нче санлы приказы белән расланган нигезнамәсенең 5 пунктына таянып, дәресләр бәйрәм көннәренә туры килү сәбәпле, 4 нче а сыйныфында дәресләр сәгатьләрне берләштерү исәбенә программа үтәлә.

**Укыту предметының темаларының эчтәлеге**

| № | Бүлек | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Тылсымлы  әкият кануннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан кичереп,бүгенге тормыш белән бәйлибез | 20 |
| 2 | Фольклорга нигезләнгән хикәяләү. Дастан, риваять һәм легендалар аша тарих белән танышабыз. | 10 |
| 3 | Шагыйрьләр һәм рәссамнар иҗаты аша табигать һәм кешеләрнең матурлыгын аңларга өйрәнәбез. | 11 |
| 4 | Безгә кадәр яшәгән яшьтәшләребез тормышы белән танышабыз. | 7 |
| 5 | Матурлыкның безгә ничек тәэсир итүен аңларга тырышабыз. | 13 |
| 6 | Җирдә кеше булу өчен, кеше күпме юллар үтә. | 18 |
| 7 | Сәнгать дөньясының үзенә генә хас үзенчәлекләрен ачыклыйбыз. | 7 |
| 8 | Үткәне булмаган халыкның киләчәге юк.Туган ил турында уйланабыз. | 16 |
|  | Барлыгы | 102 |

## Эчтәлек

**Халык авыз иҗаты.**

**Мифлар турында гомуми күзаллау булдыру.**

Борынгы халыкларның тормышы, кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәт. Тормыш агачы. Тотем хайван һәм үсемлекләр, кешеләрнең аларга карашы, борынгы традицияләрнең сакланышы.

**Тылсымлы әкиятләр.**

Дөнья турында борынгы күзаллаулар чагылышы. Тылсымлы әкият герое. Тылсымдөньясы. Тылсымлы предметлар, сихри саннар, сүзләр, тылсымлы булышчылар, тылсымлы әкият законнары: әкият герое өеннән чыгып китә. Максатка ирешү юлы (тылсымдөньясы, карурманнар аша үтүче юл, сынаулар, тылсымлы булышчы ярдәме, җиңү шатлыгы.) Халык әкиятләренең  мифлар, легендаларда чагылышы.

**Риваять һәм легендалар.**

Риваять һәм легендаларда сөйләнгән геройлар, аларның кичерешләре. Тарихи бәйләнеш. Төрле атамалар. Аларның килеп чыгышы.Риваять һәм легендаларда бирелгән вакыйгаларның әкиятләрдә чагылышы.

**Автор әкиятләре.**

Автор әкиятләренең  халык әкиятлре белән охшашлыгы (жанр һәм  сюжет). Халык әкиятлрендәге тылсым юлы белән җиңүләр, автор әкиятләрендә акыл белән эш итеп уңышка ирешү, ярату һәм яратыла белүнең көче.

**Фольклор жанрының тормышта, хәзерге вакытта яшәеше.**

Халык традицияләре һәм бәйрәмнәре. Символик төшенчәләр. Гимннар (Татарстан гимны). Халык һәм автор әкиятләре.

**Хикәя.**

Хикәя жанры турнда күзаллау формалаштыруны дәвам итү. Хикәя геройлары, аларның портреты һәм характер үзенчәлекләренең башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырмача характеристика. Герой яшәгән тирәлек, пейзаж.Хикәядәге чынбарлык чагылышы. Әдәби тел берәмлекләре.

**Әкият һәм хикәя жанрының үзгәлеге турында күзаллау формалаштыру.**

Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы-тыңлауга табигый көчләрнең серен, әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройлары-ның характерларында тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү.

**Шигърият.** Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып күзаллау. Әйләнә-тирә дөнья матурлыгын шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуын инандыру. Шагыйрьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет.

Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру,контраст,җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре:темп,тавыш көче,тон,сөйләм мелодикасы(тавышны күтәрү ,түбәнәйтү).

**Әсәр авторлары турында.**

Шагыйрь, язучы, рәссамның биографиясе.

а) әсәрдә авторлар кичереше;

ә) автор күзәтүләренең чагылыш;

б) хәзерге заман авторлары белән очрашу, балаларның авторга сораулары, җаваплар.

**Библиографик культура формалаштыру.**

Эчтәлек бите белән танышу, аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү, кече яштәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эчтәлген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп өч элементын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру. Төрле җыентыклар төзергә өйрәнү.

**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру.**

Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру *( интонация, тон, темп саклап кычкырып уку)*. Автор бирергә теләгән картинаны күзал-лау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда, үз урыныңны белеп, чират буенча уку. Укылган әсәргә анализ ясау. Уку техникасын үстерү

**Уку предметы эчтәлегенең рухи кыйммәтләре**

Патриотизм, гражданлык кыйммәте – Туган якка, татар халкына, Татарстанга мәхәббәт хисе; Ватанга хезмәт итү.

Табигать кыйммәте – туган җир; табигатькә карата мәхәббәт, сакчыл караш хисе.
Матурлык кыйммәте – матурлык, гармония; кешенең эчке дөньясы; эстетик үсеш.
Яхшылык кыйммәте – кайгыртучанлык һәм йомшак мөгамәлә; кешеләрне, тормышны ярату хисе.
Хезмәт, уку процессына иҗади якын килү кыйммәте - хезмәткә хөрмәт; максатчанлык, сакчыллык, сабырлык кебек сыйфатларны булдыр

**Укыту предметының үзләштерүнең шәхси, метапредметлы һәм предметлы нәтиҗәләр**

**4 нче сыйныфны тәмамлаган укучыларның белеме,**

**эш осталыгы һәм күнекмәләренә таләпләр**

1. Әсәрне сүзләрне дөрес итеп әйтеп, кычкырып һәм эчтән укый белү;
2. Әсәрнең мәгънәви кисәкләре арасындагы бәйләнешне ачыклау, төп фикерне билгеләү һәм аны үз сүзләрең белән әйтеп бирү;
3. Төрле авторларның 6-8 шигырен яттан сөйләү;
4. Кыска күләмле әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү;
5. Тылсымлы һәм хайваннар турындагы әкиятләрне, мәсәлләрне аера белу;
6. Әсәрдәге төп геройны характерлау, төрле әсәр геройларына чагыштырма характеристика;
7. Укылган әсәрдән чагыштыру, җанландыру, контрастны таба белу;
8. Сүзлекләрдән файдалану, тематик сүзлекләр төзү;
9. Аерым бер элементы буенча китапта ориентлашырга ойрәтү *( авторы , исеме, “Эчтәлек” бите, иллюстрацияләр)*
10. Фольклор жырын аеру: хайваннар турындагы. Тылсымлы әкиятләрне өйрәнү, мәсәл,хикәя турында күзаллау, халык иҗаты әсәрләре һәм автор әсәрләрен төркемли белү.

**Укучы түбәндәгеләрне белергә тиеш:**

- 4-5 татар, рус, чит ил классигынын исемен, аларның әсәрләрен;
- 4-5 хәзерге заман язучысы яки шагыйренең исемен, алар язган рубрикаларны;
- Үзенә иң ошаган авторның берничә әсәрен.

**Алынган белемнәрне көндәлек тормышта куллану**

- китапның, төрле элементларнына карап, эчтәлеген билгеләү;

- мөстәкыйль рәвештә уку өчен китап сайлау;
- укылган әсәр геройларын тасвирлап сөйләү;
- сүзлекләрдән кирәкле мәгълүматны табу.

**Уку елы ахырына универсаль уку гамәлләре формалаштыру. УУГ**

**Шәхси нәтиҗәләр**.

**Шәхси универсаль уку гамәлләре**:

- "Гаилә", "туган ил", "мәрхәмәтлелек", "башкаларга карата түземлелек" төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү;
- Туган республикага, гаиләгә, туганнарга карата хөрмәт, әти-әнине ярату; үз милләтеңне ярату, татар булуың белән горурлану;
- укуга карата кызыксыну хисе булу, укучы ролен үзләштерү;
- әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләрен һәм геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;

**Предметара нәтиҗәләр.**

**Регулятив универсаль уку гамәлләре**:

- Эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү.
- Укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү.
- Укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү.
- Эш сыйфатына бәя бирә белү.

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**

- Дәреслек белән эш итә белү.
- Хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, әкиятне) сәнгатьле итеп уку.
- Этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны, сүзлекләр кулланып, аңлап уку.
- Текстта очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсен төшенү.
- Текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү.
- Укытучының авыр булмаган сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны дәреслектән таба белү.
- Предметларны, чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели  белү

- Укылган яки тыңланган зур булмаган текстның эчтәлеген сөйли белү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

- Дәрестә һәм төрле ситуацияләрдә диалогта катнаша белү
- Укытучының, классташларның сорауларына җавап бирү;
- Сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт белдерә белү.
- Башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү.
- Парларда эшли белү.

**4нче сыйныфны тәмамлаганда укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:**

**Уку күнекмәләре.**

Дөрес, аңлап, тиешле дәрәҗәдә йөгерек һәм сәнгатьле уку. Интонацияне (тизлек, логик басым, пауза, тон) текст эчтәлегенә бәйле рәвештә сайлау.

Уку тизлеген сүзне тулы һәм төгәл күрергә, тиз аңларга өйрәтү исәбенә үстерү. Эчтән уку алымына зур күләмле һәм күптөрле текстларны укытып өйрәтү. Сәнгатьле уку осталыгын камилләштерү. Авазларны ачык һәм дөрес әйтүгә ирешү. Укыганда орфоэпия нормаларын үтәү, уку тизлеген эчтәлекка бәйле рәвештә сайлау, аны арттыра һәм киметә белү, сөйләм максатына карап, тавышны көчәйтеп һәм пышылдап уку. Әдәби әсәрләрне рольләргә бүлеп укырга һәм сәхнәләштерергә өйрәтү.Сәнгатьле укуга хәзерләнә белү: эчтәлекне аңлау, сурәтләнгән күренешне ачык итеп күз алдына китерү, фраза һәм шигырь
юлларының яңгырашын ишетү, ритмын отып алу, башкару максатын аңлау.

**Текст өстендә эшләү.**

Әсәрне тыңлаганда һәм укыганда төп фикерне тотып ала белү, хикәяләүнең логикасын, тексттагы мәгънәви һәм интонацион бәйләнешне аңлау. Вакыйгаларның эзлеклелеген, узара бәйләнешен билгеләү. Сүзле картина элементлары кертеп, укылган текстның эчтәлеген тулысынча, сайлап һәм кыскача сөйләү, җавапның дөреслеген тексттан өзекләр укып раслау. Текстны мөстәкыйль рәвештә мәгънәле кисәкләргә бүлү һәм аларда чагылдырылган төп фикерне таба алу. Укытучы ярдәмендә план төзү, эчтәлеген сөйләү. Кешеләрне, табигатьне һәм вакыйгаларны сүрәтләү өчен автор кулланган сүзләрне табу. Әсәр геройларының эш кылынышларына, уй – хисләренә һәм алар нигезендә яткан сәбәпләргә укытучы ярдәмендә бәя бирә белү. Әдәби әсәрнең тел чараларына игътибарлы булу, андагы сурәтләү чараларын аңлау. Шигъри сүзгә

игътибарлы, сизгер булу, текстан эпитет, чагыштыру, метафораларны табу, чагыштыруга вариантлар сайлау, метофораны читләтеп әйтү чарасы итеп аңлый һәм бәяли белү.

Мәктәп, сыйныф тормышын күзәтүләр нәтиҗәсендә хикәяләр төзү. Үз сөйләмеңне планлаштыра белү, соңыннан тикшерү һәм, сөйләм максатын исәпкә алып, төзәтмәләр кертү. әкият һәм хикәяләр сюжетына үз вариантларыңны уйлап табу, әсәр геройларының урыннарын алмаштыру, аларны гадәти булмаган хәлләргә кую. Сюҗет үсешен алдан билгели алу, исеме һәм башламы буенча китапның темасын, якынча эчтәлеген билгеләү.

Балалар белергә тиешле әдәби жанрлар: әкият һәм хикәя, шигырь һәм мәсәл, халык аваз иҗаты әсәрләре (табышмак, мәкаль, җыр, әйтем, уйды

**4 нче сыйныфта укыла торган әсәрләр**

**Халык авыз иҗаты.**

“Җир ничек яралган?” (легенда), “Күкнең күтәрелүе (хикәят), “Айдархан һәм сәхабәләр, (легенда), “Пәйгамбәрнең тууы һәм аның балачагы”, “Абага чәчәге (хикәят), “Ак бүре”(риваять), “Кырык кыз”( риваять), “Мәрҗан каласы һәм унике кыз” (хикәят), “Дөнья яратылу турында” (миф), “Хапи алла турында” (миф), “Чыршы ни өчен мәңге яшел?” (легенда) . әкиятләр: “Ак байтал”,“Ак бүре”, “Еланнар патшасы Шаһмара”, “Үги кыз” , “Ике кыз”, “Бумеранг”(Австралия халкы әкияте).

Борынгы язучылар һәм татар әдәбияты классиклары

Кол Гали “Кыйссаи Йосыф”.Г. Тукай : “Таз”, “Яз галәмәтләре”.Дәрдемәнд: “Гали”.З. Ярмәки: “Иртә”, “Ак каен”.М.Җәлил: “Дару”.К.Насыйри. “Каз итен коймакка төреп,каймакка манып ашау”. Н.Исәнбәт: “ Кышкы төндә”, “Туган ил”, “Өч матур сүз”.Ш.Бабич: “ Тын төн”, “Габдулла әфәнде Тукай”. .А. Алиш. “Сертотмас Үрдәк”.Г.Кутуй.” Яшен”.Ш.Галиев:”Кол Галигә”, “Алсу дөнья”, “Җирдә миңа ни кирәк?”, “Урман ява”, “Тукран сые”.Г.Ибраһимов: “ Укудан кайткач”.Г.Галиев.” Бибкәй аланы”.Ф.Әмирхан. “ Кечкенә хезмәтче”.К.Нәҗми: “Нәсимәнең беренче эш көне”.З.Бәшири: “ Бер асрауның аһ-зары”.Н.Думави: “ “Беренче кар”, “Ятим бала”.М.Мәһдиев: “Бәхилләшү”.С.Хәким: “ “Яратам мин”, “Тегермән стенасындагы язулар”.Ә.Фәйзи :”Асрарга бала бирәм”.Ф.Хөсни:”Малай белән солдат”.Ш.Рәкыйпов: “ Төнге очыш”.И.Туктар: “Букет”, “Бер каен үсә”.Г.Хәсәнов: “ Аккош”, “Абага”.Г.Сабитов:“Кадерле ул туган як!”, “Чәчәк нигә боекты?”.Н.Арсланов: “Халкыма”.Җ.Тәрҗеманов: “Шуктуган”, “Тукран малае Шуктуган”.Л.Ихсанова : “ Шомырт чәчәкләре ак кына”.Ф.Яруллин: “Буар

елан”.М.Әгъләмов: “Матурлык минем белән”.Зөлфәт: “Кыз тавы”.С.Шакир: “ Ландыш чәчәге”.Р.Хафизова: “Кирлемән”.Г.Латыйп: “Минем нәсел”.Р.Гыйззәтуллин: “Язгы моң”.К.Тимбикова: “Бану әби сабагы”.К.Сибгатуллин: “Чыпчык”, “Бөтен кеше бүген шундый әйбәт”.Роб.Әхмәтҗанов: “Безнең шигырь”.Р.Хисмәтуллин: “Аһ. Бер китсә кирегә...”

Рус язучылары:

Л. Толстой “Слива төше”.

Н. Сладков: “Тыштан ялтырый. эчтэн калтырый».

**Татар язучылары һәм шагыйрьләре (бүгенге көн язучылары)**

Р. Миңнуллин: “Иртән иртүк”, “Атказанган сандугач”, “Машина тавышлы көчек турында кечкенә әкият”, “Сабантуйда”, “Татарларым”, “Минем телем”, “Утыз Имәнине укыганда туган уйлар”.Р. Фәйзуллин: “Быелгы яз”, “Минем эти”.Х.Камалов: “ Археолог”.Ә.Рәшит: “ Нәсел агачы”.К.Булатова:”Кичә генә”, “Шушы яктан, шушы туфрактан без”.Җ.Дәрзаман: “Бөҗәкләр белән сөйләшү”. Р. Вәлиева: “Изгеләр тавы”, Энҗе чәчәк”. “Бөтен дөнья ак кына”, “Онытма!”.Р. Вәлиев: “Кошлар кайта”, “Кайтчы, Сөембикә”, “Эт кояшы” (өзек), “Ватаным”.Н. Әхмәдиев: “Хәерле иртә”.И.Гыйлаҗев: “Тутыкмас тотка”, “Охшашлык”.Р.Харис: “Татарстан әләме”, “Зөләйха”, Ак карлар арасында”, “Елмай”, “Туган җирем”, “Фронтовиклар”.Л. Лерон: “Кыхмырый, Мыхмырый һәм Шыхмырый”.Э. Шәрифуллина “ Табигатьнең бер бөртеге”, Без татар балалары”, “Тормыш яме”. Г. Гыйльманов: “ Чишмәгә бардык”, Кайтаваз”, “Курай”, “Җавапсыз легенда”, “Минем исемем – Бүрек”.В. Нуриев: “Ачуланма инде. Илһам!”,Г. Рәхим:”Көз йөри”, “Көзге моң”, “Көзге урман”, “Песнәк”, “Апрель”.Р. Корбан: “Көз нинә моңлы?”, “Ярдәм итик”, “Курай”.Йолдыз: “ Очрашу”.Р.Мингалим: “ Бүген төнлә күккә кара”.Батулла: “ Су иялəре”(әкият), “Терек-терек кырмыска”, “Салават күпере кайда йоклый?”В.Хәйруллина “ Хәерле көн”, “Алмаштыру”,“Наз”, “Чикерткә”.М.Мирза: “ Көз”, “Балачак хатирәсе”.Ф.Бәйрәмова: “Кара пулат”.Мөҗәһит: “Бер яфрак зары”.Д.Гайнетдинова: “Исәнме, яңа көн”, “Батыр Хәбир”.Л.Гыймадиева: “Кара урман, караңгы төн”. Н.Сәйяр: “ Айсылу”.Р.Рахман: “ Кесәл”. Н.Каштан: “ Әрем исе”.Г.Вәлиева: “Кызыктырсалар да”, “Карт алаша колагы”.Ф.Тарханова: “Без бәлеш пешерәбез”, “Килде пилмән ашыйсы”. И Нәбиуллина: “Тәмле тел”.Ф. Мәҗитов: “Яңгыр кызы Гөлтамчы”.Г.Мөхәммәтшин: “ Туган як”.М.Галиев: “ Туган як”.Г.Морат: “ Чит тел”.С.Гаффарова: “Көз”. Р.Зәйдулла: “Кол Гали”.

## Тематик планлаштыру
## Әдәби уку

| № | Дәрес темасы | Укучыларның эшчәнлеге төре һәм эшформалары | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт |
| 1 | Җир йөзендә яшәгән беренче кешеләр | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. Кроссворд чишү. | 2.09 | |
| 2 | Җир ничек яралган? (легенда) | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау.. Энциклопедиядән өстәмә материал табу. | 4.09 | |
| 3 | Борынгы легендалар ни сөйли? “Күкнең күтәрелүе” | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау.. Энциклопедиядән өстәмә материал табу. | 6.09 | |
| 4 | Тотем агачлар | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. Кроссворд чишү. | 9.09 | |
| 5 | Пәйгамбәрнең тууы. | Әсәрне сәнгатьле уку. Текстка якын сөйләү. Әсәрнең төп героена характеристика бирү. Әсәргә ясалган иллюстрациягә карап сөйләү,анализ бирү. | 11.09 | |
| 6 | Туган як сылуы – ак каен | Өзекне анализлап сөйләү.<br>Сорауга җавап табу,бирү. Укылган әсәргә иллюстрация ясау. Әсәргә ясалган иллюстрациягә карап сөйләү,анализ бирү. | 13.09 | |
| 7 | Туган як сылуы – ак каен | Шигырьне,әсәрдән өзекне ятлау. Өзекне анализлап сөйләү.<br>Сорауга җавап табу,бирү. Укылган әсәргә иллюстрация ясау. Әсәргә ясалган иллюстрациягә карап сөйләү,анализ бирү. | 16.09 | |
| 8 | Абага чәчәге. Г.Кутуй “Рөстәм маҗаралары” | Әсәрне сәнгатьле уку. Шундый ук башлам өлеше һәм геройлар белән әкият язу. Әсәргә табышмак уйлау,җавабын табу. Текстка якын сөйләү. | 18.09 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9 | Абага чәчәге. Г.Кутуй “Рөстәм маҗаралары” | Әсәрне сәнгатьле уку. Шундый ук башлам өлеше һәм геройлар белән әкият язу. Әсәргә табышмак уйлау,җавабын табу. Текстка якын сөйләү. | 20.09 | |
| 10 | Тотем хайваннар. “Ак байтал” (татар халык әкияте) | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. Кроссворд чишү. | 23.09 | |
| 11 | Тотем хайваннар. “Ак байтал” (татар халык әкияте) | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. Кроссворд чишү. | 25.09 | |
| 12 | Татар мифологиясендә Ак бүре. Татарстан гербы. | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Видеофильм карау. Энциклопедиядән өстәмә материал табу. | 27.09 | |
| 13 | Ак бүре (Татар халык әкияте) | Әсәрне сәнгатьле уку. Шундый ук башлам өлеше һәм геройлар белән әкият язу. Әсәргә табышмак уйлау,җавабын табу. Текстка якын сөйләү | 30.09 | |
| 14 | Ак бүре (Татар халык әкияте) | Әсәрне сәнгатьле уку. Шундый ук башлам өлеше һәм геройлар белән әкият язу. Әсәргә табышмак уйлау,җавабын табу. Текстка якын сөйләү | 2.10 | |
| 15 | Ак бүре (Татар халык әкияте) | Әсәрне сәнгатьле уку. Шундый ук башлам өлеше һәм геройлар белән әкият язу. Әсәргә табышмак уйлау,җавабын табу. Текстка якын сөйләү. | 4.10 | |
| 16 | Әкиятләрдә Ак елан. | Әсәрне сәнгатьле уку. Текстка якын сөйләү. Сорауга җавап табу,бирү. Әсәрнең төп героена характеристика бирү. | 7.10 | |
| 17 | Ф. Яруллин “Буар Елан” | Әсәрне сәнгатьле уку. Текстка якын сөйләү. Сорауга җавап табу,бирү. Әсәрнең төп героена характеристика бирү. | 9.10 | |
| 18 | Еланнар патшасы Шаһмара. | Әсәрне рольләргә бүлеп уку.<br>Укылган әсәргә иллюстрация ясау. Әсәрнең төп героена характеристика бирү. Өзекне анализлап сөйләү. | 11.10 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 19 | Еланнар патшасы Шаһмара. | Әсәрне рольләргә бүлеп уку.<br>Укылган әсәргә иллюстрация ясау. Әсәрнең төп героена характеристика бирү. Өзекне анализлап сөйләү. | 14.10 | |
| 20 | “Тылсымлы әкият ка-нуннарын өйрәнәбез: үткәннәрне яңадан кичереп, бүгенге тормыш белән бәйлибез”темасын йомгаклау | Сорауларга жавап бирү (тест) | 16.10 | |
| 21 | Борынгы шагыйрь Кол Гали. | Борынгы шагыйрь Кол Гали<br>иҗаты белән таныштыру, аның төрле шигырьләренең язылу стилен өйрәнү | 18.10 | |
| 22 | Кыссаи Йосыф. | Борынгы шагыйрь Кол Гали<br>иҗаты белән таныштыру, аның төрле шигырьләренең язылу стилен өйрәнү Шигырьне,әсәрдән өзекне ятлау. Өзекне анализлап сөйләү. | 21.10 | |
| 23 | Без – татар балалары. Г. Латыйпның “Минем нәсел”, Э. Шәрифуллинаның “Без – татар балалары” | Көзге табигать мизгелләре<br>нең автор әсәрләрендә би-релешен өйрәнү, чагыш-тыру, сынландырулар, строфа турында белем-нәрне ныгыту | 23.10 | |
| 24 | Нәсел агачы. | Нәсел агачы, нәсел шәҗәрәсе турында белү.<br>-Бик борынгы нәсел шәҗәрәсе үрнәкләре белән танышу. | 25.10 | |
| 25 | Су асты патшалыгында.<br>Н. Сәйяр “Айсылу” | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. Кроссворд чишү. | 28.10 | |
| 26 | Су асты патшалыгында.<br>Н. Сәйяр “Айсылу” | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. Кроссворд чишү. | 6.11 | |
| 27 | Су кызы. | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. | 8.11 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 28 | Айсылу – бәхетле бала. | Әсәрне сәнгатьле уку. Текстка якын сөйләү. Әсәрнең төп героена характеристика бирү. Әсәргә ясалган иллюстрациягә карап сөйләү,анализ бирү. | 11.11 | |
| 29 | Айсылу – бәхетле бала. | Әсәрне сәнгатьле уку. Текстка якын сөйләү. Әсәрнең төп героена характеристика бирү. Әсәргә ясалган иллюстрациягә карап сөйләү,анализ бирү. | 13.11 | |
| 30 | Г.Гыйльманов “Җавапсыз легенда» | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Язучы турында видеофильм карау. Энциклопедиядән өстәмә материал табу. | 15.11 | |
| 31 | Җирдә миңа ни кирәк? | “Кеше яшәеше өчен ниләр кирәк?” соравына җавап табу. Укучыларны сән.укуга хәзерләү Уңай һәм тискәре геройларны аеру.<br>Геройларга характеристика бирү. | 18.11 | |
| 32 | Шәехзадә Бабич шигырьләре. | XX гасыр башында яшәп иҗат иткән шагыйрьләр-нең берсе булган Шәехза-дә Бабич иҗаты белән таныштыру, аның төрле шигырьләренең язылу стилен өйрәнү | 20.11 | |
| 33 | Көзге табигать мизгелләре. | Көзге табигать мизгелләре<br>нең автор әсәрләрендә би-релешен өйрәнү, чагыш-тыру, сынландырулар, строфа турында белем-нәрне ныгыту | 22.11 | |
| 34. | Көзге табигать мизгелләре. | Көзге табигать мизгелләре<br>нең автор әсәрләрендә би-релешен өйрәнү, чагыш-тыру, сынландырулар, строфа турында белемнәрне ныгыту | 25.11 | |
| 35 | Кышкы сандугач. | Укучыларны безнең якта кышлаучы кошлар белән таныштыруны дәвам итү; | 27.11 | |
| 36 | Иртә яме, иртә моңы- җан азыгы. | Укучыларны режим белән яшәргә күнектерү | 29.11 | |
| 37 | Иртә яме, иртә моңы- җан азыгы. | Укучыларны режим белән яшәргә күнектерү | 2.12 | |
| 38 | Әнкәм портреты. | Галәмдә табигать һәм кешенең бербөтен булуын, кеше һәм табигать арасын-да бәйләнешләрне аңлату, туган як кадерен хәтта хайваннар да белүен төшендерү | 4.12 | |
| 39 | Иң матур сүз. | Сүз көче, сүзне уйлап әй-тергә кирәклеген аңлату.<br>Тәмле телле, ихлас сүзле шәхес тәрбияләү. | 6.12 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 40 | Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә. | Икенче һәм өченче сый-ныфларда өйрәнгән язу-чылар иҗатын искә төше-реп, яңа әсәрләре белән таныштыру барышында иҗат үзенчәлекләрен бил-гели белергә өйрәтү | 9.12 | |
| 41 | “Шагыйрьләр һәм рәссамнар иҗаты аша та-бигать һәм кешеләрнең матурлыгын аңларга өйрәнәбез”бүлеген кабатлау | Укучыларның тема буенча<br>белем һәм күнекмәләрен системага салу | 11.12 | |
| 42 | Газаплы язмыш. | Борынгы заманнарда яшәгән балалар тормышының үзенчәлекле якларын, авыр тормышта яшәү сәбәпләрен аңлату | 13.12 | |
| 43. | Кечкенә хезмәтче. | Ф.Әмирханның”кечкенә хезмәтче” хикәясе аша ба-лаларның авыр хезмәте бе-лән таныштыру, әсәргә ка-рата мөнәсәбәтләрен ачык итеп аңлата белүләренә ирешү | 16.12 | |
| 44. | Күз яшьле балачак. | Тема уртаклыгын табу, дәлилләп аңлата алуларына ирешү | 18.12 | |
| 45 | Д.Аппакова “Кечкенә Бануның тарихы” | Тема уртаклыгын табу, дәлилләп аңлата алуларына ирешү | 20.12 | |
| 46 | Каникуллар- рәхәт вакыт. | Кышкы каникул көннәре, бу вакытның ни өчен бик рәхәт булуын ачыклау | 23.12 | |
| 47 | Балачак хатирәләре. | Һәрбер кешенең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге булуга инандыру. Шул вакыт эчендә сагынып искә алырлык мизгелләр булуы турында ажлату. | 8.01 | |
| 48 | Матурлык дөньяны коткара. | Зөлфәт һәм М.Мәһдиев әсәрләре белән таныштыру | 10.01 | |
| 49 | Көннәрем гөрләп торсын. | Көнне исәнләшү, хәерле иртә теләүдән башласаң, һәр эшең уңай булыр, максатыңа да ирешә алачаксың, дип балаларны инандыру. | 13.01 | |
| 50 | Каен – урман чибәре. | Татар халкы борын-борын-нан табынган , тормышта еш файдаланган каен ага-чы турында өйрәнүне дәвам итү | 15.01 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 51 | Каен – урман чибәре. | Татар халкы борын-борын-нан табынган , тормышта еш файдаланган каен ага-чы турында өйрәнүне дәвам итү | 17.01 | |
| 52 | Бөтен дөнья ак кына. | Табигатьнең иң саф, гүзәл мизгелләрнең берсе – кыш турында күзаллауларын үстерү. Авторларның та-бигать фасылларына ба-гышланган әсәрләре белән танышу | 20.01 | |
| 53 | Язгы моң. | Язгы табигать күренешлә-рен тасвирлаган әсәрләр уку, рәссам М.Хәйрет-динов иҗаты белән танышу. | 22.01 | |
| 54 | Серле күк. | Күк йөзенең серләрен әдәби әсәрләр аша ачу | 24.01 | |
| 55 | Матурлык дөньясы. | Матурлыкны аңлый, аңа соклана, саклый белү телә-ге уятырлык әсәрләр белән танышу | 27.01 | |
| 56 | Туган як – Идел көзгесендә. | Татарстанның горурлыгы, байлыгы булган Идел ел-гасы турында белемнәрне арттыру | 29.01 | |
| 57 | Туган көнгә – салават күпере | Укучыларны туган көннең кешеләр тормышында зур, эчтәлекле бәйрәм итеп билгеләп үтелүен күрсәтү. | 31.01 | |
| 58 | Табигать – серле дөнья | Балаларга табигать серлә-рен ачарга ярдәм итү | 3.02 | |
| 59 | Батулла “Терек-терек кырмыска” | Балаларга табигать серләрен ачарга ярдәм итү | 5.02 | |
| 60 | Аккошлар-сак кошлар. | Г.Хәсәнов иҗаты белән таныштыру, аның күзәтүләре аша аккошлар тормышы белән танышу | 7.02 | |
| 61 | Сандугач – табигать җырчысы. | Табигатьнең гүзәл җырчы-сы – сандугач белән тан-ыштыру. Авторларның аларга багышлап язган әсәрләрен уку | 10.01 | |
| 62 | Тылсымлы, кодрәтле үлән. Г.Хәсәнов “Абага” | Абага үсемлеге, аның хикмәтләре белән таныштыру. | 12.02 | |
| 63 | Тылсымлы, кодрәтле үлән. Г.Хәсәнов “Абага” | Абага үсемлеге, аның хикмәтләре белән таныштыру. | 14.02 | |
| 64 | Кирлемән маҗаралары | Кешедәге кирелек сыйфа-тының тискәре күренеш булуын, үз-үзеңне тәртип-ле, инсафлы тотарга кома-чаулык итүен төшендерү | 17.02 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 65 | Кирлемән маҗаралары | Кешедәге кирелек сыйфа-тының тискәре күренеш булуын, үз-үзеңне тәртип-ле, инсафлы тотарга кома-чаулык итүен төшендерү | 19.02 | |
| 66 | Урман докторы. | Табигатьнең күркәм бер кошы-тукран белән та-ныштыру. Аның яшәеше, кешеләргә китергән фай-дасы турында күзаллау булдыру | 21.02 | |
| 67 | Урман докторы. | Табигатьнең күркәм бер кошы-тукран белән та-ныштыру. Аның яшәеше, кешеләргә китергән фай-дасы турында күзаллау булдыру | 24.02 | |
| 68 | Гөмбәләр серен белү кирәк. | Табигать үсә торган күптөрле гөмбәләр семялыгыннан ашарга яраклы гөмбәләрне танырга өйрәтү | 26.02 | |
| 69 | Гөмбәләр серен белү кирәк. | Табигать үсә торган күптөрле гөмбәләр семялыгыннан ашарга яраклы гөмбәләрне танырга өйрәтү | 28.02 | |
| 70 | Бану әби сабагы. | Язучы Кояш Тимбикова әсәрләре белән танышу | 3.03 | |
| 71 | Бану әби сабагы. | Язучы Кояш Тимбикова әсәрләре белән танышу | 5.03 | |
| 72 | Аш пешерү хикмәтләре. | Кояш Тимбикованың “Бану әби сабагы” хикәясе белән танышуны дәвам итү | 7.03 | |
| 73 | Татар халык ашлары. | Татар халкының милли ризыклары белән язучы һәм рәссамнар иҗаты ярдәмендә таныштыру, гореф-гадәтләрен аңлату | 10.03 | |
| 74 | Балалар дөньясы. | Г.Гыйльманов, Д.Гайнет-динова, Л.Гыймадиева әсәрләрендә балалар тормышының чагылышы белән таныштыру, авторларның ни әйтергә теләвен ачыклау | 12.03 | |
| 75 | Бүрек-нәни көчек. | Г.Гыйльмановның “Минем исемем бүрек” әсәре белән танышу дәвам итү | 14.03 | |
| 76 | Бүрек-нәни көчек. | Г.Гыйльмановның “Минем исемем бүрек” әсәре белән танышу дәвам итү | 17.03 | |
| 77 | Бүрек-ышанычлы сакчы. | Г.Гыйльмановның “Минем исемем бүрек” әсәренең төп идеясен аңлауларына ирешү | 19.03 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 78 | Бүрек-ышанычлы сакчы. | Г.Гыйльмановның “Минем исемем бүрек” әсәренең төп идеясен аңлауларына ирешү | 21.03 | |
| 79 | “Җирдә кеше булу өчен, кеше күпме юллар үтә” бүлеген йомгаклау | Уңай һәм тискәре геройларны аеру.<br>Геройларга характеристика бирү. | 24.03 | |
| 80 | “Серле ачкыч” мәктәп клубы утырышы (китапханәгә экскурсия) | Укучыларны якташ язучылар иҗаты, тормыш юлы белән таныштыру | 4.04 | |
| 81 | Бәбкә үстерү кыенлыклары | Сәнгать дөньясының үзенә хас үзенчәлекләрен аңлату | 7.04 | |
| 82 | Чыпчыкның да үз җыры бар | Гади генә күренешләрдән дә матурлыкны күрә һәм бәяли белергә өйрәтү | 9.04 | |
| 83 | Яз галәмәтләре | Язгы табигать мизгелләрен яктырткан әсәрләр аша табигатьтәге үзгәрешләр-не, язның төп билгеләрен табарга өйрәтү, кеше күңе-ленең кайсы халәтен яз белән чагыштыруларын аңлату | 11.04 | |
| 84 | А.Алиш “Сертотмас үрдәк” | Уңай һәм тискәре геройларны аеру.<br>Геройларга характеристика бирү. | 14.04 | |
| 84 | А.Алиш “Сертотмас үрдәк” | Уңай һәм тискәре геройларны аеру.<br>Геройларга характеристика бирү. | 16.04 | |
| 85 | А.Алиш “Сертотмас үрдәк” | Уңай һәм тискәре геройларны аеру.<br>Геройларга характеристика бирү. | 18.04 | |
| 87 | Һәркемгә үз Ватаны кадерле | Ватан төшенчәсен бала-ларның ничек аңлавын ачыклау, аны сакларга һәм якларга кирәклекне аңлату | 21.04 | |
| 88 | Татарстан флагы | Дәүләт символлары турында мәгълүмат бирүне дәвам итү | 23.04 | |
| 89 | Зур тарихлы батыр халкым | Татар халкының тарихи<br>үткәненә багышланган әсәрләр белән таныштыру-ны дәвам итү | 25.04 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 90 | Г.Вәлиева “Карт алаша колагы”. | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. | 28.04 | |
| 91 | Балачакның онытылмас мизгелләре | Элекке заманнарда яшәгән балалар тормышы аша илебез тарихын аңлату | 30.04 | |
| 92 | Авыр елларда | Сугыш чоры балалары кичергән авырлыкларны әдәби образлар язмышы ярдәмендә аңлату | 2.05 | |
| 93 | Н.Каштан “Әрем исе” | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. | 5.05 | |
| 94 | Сөю – иң куәтле дәва | Укучыга уку эшчәнлегенә кереп китү өчен, шартлар булдыру. Темага бәйле фикерләрен төгәл, ачык итеп әйтә белергә өйрәтү | 7.05 | |
| 95 | Кыю очучылар | Укучыга уку эшчәнлегенә кереп китү өчен, шартлар булдыру. Темага бәйле фикерләрен төгәл, ачык<br>итеп әйтә белергә өйрәтү | 9.05 | |
| 96 | Кыю очучылар | Укучыга уку эшчәнлегенә кереп китү өчен, шартлар булдыру. Темага бәйле фикерләрен төгәл, ачык<br>итеп әйтә белергә өйрәтү | 12.05 | |
| 97 | Ш.Рәкыйпов “Төнге очыш” | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. | 14.05 | |
| 98 | Һәркемгә якын ул туган як | Туган җирне, туган якны ярату турында сөйләшү Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. | 16.05 | |
| 99 | Якташ язучылар иҗатын өйрәнәбез | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. | 19.05 | |
| 100 | Якташ язучылар иҗатын өйрәнәбез | Әсәрне сәнгатьле уку. Аңлатмалы сүзлек белән эш. Презентация карау. Әсәргә план төзү,шул план буенча сөйләү. | 21.05 | |
| 101 | “Серле ачкыч” мәктәп клубы утырышы.Арадаш аттестация. | “Серле ачкыч” мәктәп клубының чираттагы утырышы | 23.05 | |
| 102 | Ел буе өйрәнгәннәрне йомгаклау. | “Серле ачкыч” мәктәп клубының чираттагы утырышы | 26.05 | |

**Әдәбият**

1. Г. М. Сафиуллина, Ф. Ф. Хәсәнова, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова. Әдәби уку: 4 нче сыйныф]: Дәреслек. 3 кисәктә. 1 кисәк. — Казан: «Мәгариф — Вакыт” нәшрияты, 2014.

2. Г. М. Сафиуллина, Ф. Ф. Хәсәнова, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова. Әдәби уку: 4 нче сыйныф: Дәреслек. 3 кисәктә. 2 кисәк. — Казан: «Мәгариф — Вакыт» нәшрияты, 2014.

3. Г. М. Сафиуллина, Ф. Ф. Хәсәнова, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова. Әдәби уку: 4 нче сыйныф: Дәреслек. 3 кисәктә. 3 кисәк. — Казан: «Мәгариф — Вакыт» нәшрияты, 2014

4. Г. М. Сафиуллина, Ф. Ф. Хәсәнова, Ә. Г. Мөхәммәтҗанова. Әдәби уку: 4 нче сыйныф: Методик кулланма. — Казан:«Мәгариф — Вакыт» нәшрияты, 2014